ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19

ГЛАВА АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

Тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**03.11.2021 ел** **№ 3**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр, Алат спиртзаводы, Гәр авылларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылында гражданнар җыенын 2021 елның 16 ноябренә 15.00 сәгатькә билгеләргә. Үткәрү урыны – Алан-Бәксәр авылы мәдәният йорты каршындагы мәйдан.

1.1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:
- Алан-Бәксәр авылында халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;
- Алан-Бәксәр авылында ял зонасы территориясен төзекләндерүне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алат спиртзаводы авылында гражданнар җыенын 2021 елның 16 ноябренә 11.30 сәгатькә билгеләргә. Үткәрү урыны – Алат спиртзаводы авылы, Үзәк урам, 33 йорт янында.

2.1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алат спиртзаводы авылы территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:
- Алат спиртзаводы авылы эчендәге урам юлларын төзекләндерү;
- Алат спиртзаводы авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тотуны (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру) буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?"

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Гәр авылында гражданнар җыенын 2021 елның 16 ноябренә 13.00 сәгатькә билгеләргә. Үткәрү урыны – Гәр авылы, Үзәк урам, 24 йорт янында.

3.1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:
"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Гәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:
- Гәр авылында контейнер мәйданчыклары төзү;
- Гәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тотуны (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру) буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?"

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина